| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Об отмене карантина, установленного на территории деревни Кара-Ширма Тюлячинского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных**

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством:

а) на территории деревни Кара-Ширма Тюлячинского района Республики Татарстан;

б) на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

улица Школьная в селе Сарлы Азнакаевского района;

улица Энгельса в селе Уразаево Азнакаевского района;

улица Подгорная в деревне Уразаево Актанышского района;

улица Ижевское шоссе в городе Елабуге;

улица Молодежная в поселке городского типа Рыбная Слобода Рыбно-Слободского района.

2. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 26 ноября 2015 года № УП-1129 «Об установлении карантина на территории деревни Кара-Ширма Тюлячинского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
27 января 2016 года
№ УП-49

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Теләче районы Карашырмә авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының Теләче районы Карашырмә авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай районының Сарлы авылындагы Мәктәп урамы;

Азнакай районының Уразай авылындагы Энгельс урамы;

Актаныш районының Уразай авылындагы Тау асты урамы;

Алабуга шәһәрендәге Ижевск шоссесы урамы;

Балык Бистәсе районының Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогындагы Яшьләр урамы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Теләче районы Карашырмә авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 26 ноябрендәге ПУ-1129 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 27 гыйнвар
№ ПУ-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ